ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

16.12.2024 — 59

Югары Ослан муниципаль районы  Октябрьский  авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә, Октябрьский авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 14 декабрендәге 1 нче номерлы һәм 2024 елның 14 декабрендәге 2 нче номерлы  карарларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш. Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Башкарма
комитетының 15.12.2024 ел №59
карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә
ГРАЖДАННАРНЫҢ ҮЗАРА САЛЫМ АКЧАЛАРЫН ҖЫЮ ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчасын түләү 2025 елның 1нче гыйнварыннан 2025 елның 31нче мартына кадәр гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм алар тарафыннан тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыен турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) 1 төркем инвалидлар

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) тыл хезмәтчәннәре

5. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан кергән акчалар Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башкарма комитеты счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша https://uslugi.tatarstan.ru/, яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Башкарма
комитетының 15.12.2024 ел №59
карарына

2 номерлы кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР ИТҮ) № _____

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и. ______________________________________________________

Адрес: _____________________________________________

_________________________________________________________________ нигездә

Сезгә _________________________ вакытына кадәр

чараларны гамәлгә ашыруга ____________________________________сум күләмендә,

түбәндәге реквизитлар буенча: _________________________________________________

БИК алучының банкы _________________________________________

Сч. № ____________________________________

Алучы ____________________________________

ИНН ______________________________________________

КПП ______________________________________________

КБК ________________ _ ОКАТО___________________

Түләүне билгеләү

____________________________________________________________________________

Җитәкчесе __________________ ___________________________________________

М. У. (имза) (имзаны киңәйтү)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Үзара салым буенча бер тапкыр бирелә торган түләүне бюджетка түләү турында хәбәрнамә (хәбәрнамә)

_____________________________________________________________

*(муниципаль берәмлекнең исеме)*

_________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф. И.А.и.

____________________________________________________________

Адрес: _______________________________________________________

Алдым «__» ________________ 20__ ел _________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә:*

*Киселә торган өлеше тутырыла һәм, хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылса, Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетында кала.*